РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

13.11.2024 — № 923-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 13 декабрендәге 1919-п номерлы карары белән расланган «Безнең яңа укытучы» гранты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Белем бирү сыйфатын күтәрү, гомуми белем бирү оешмаларының педагог хезмәткәрләренә, гомуми белем бирү оешмаларының, мәгариф оешмаларының яшь белгечләренә ярдәм итү максатларында, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының "Безнең яңа укытучы" гранты турында 2023 елның 13 декабрендәге 1919-п номерлы карары белән расланган «Безнең яңа укытучы» гранты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

**1.1.** 3 пунктның икенче абзацында «2023 елның 1 сентябренә» сүзләрен «2024 елның 1 сентябренә» сүзләренә алмаштырырга;

**1.2.** 17 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа бишенче абзац өстәргә:

«Грантны түләү Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының грант алучыга Татарстан Республикасы бюджеты хисабына «Безнең яңа укытучы» бирелгән очракта туктатыла, ә элек түләнгән грант суммасы кире кайтарылмый.».

**2.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә.

Җитәкче — М. Р. Ишниязов